**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2025 елның «02» октябреннән № 215

## 2026 елга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының сәнгати-эстетик юнәлешендә балаларга өстәмә белем бирүче мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарны раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 14 декабрендәге «Татарстан Республикасы сәнгать-эстетик юнәлешендәге балаларга өстәмә белем бирү учреждениеләрен норматив финанслауны кертү турында» 854 номерлы карары һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. 2026 елга расларга:

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының сәнгать-эстетик юнәлештә балаларга өстәмә белем бирүче мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә кушымта итеп бирелә торган норматив чыгымнарны;

балаларга сәнгать-эстетик юнәлешле өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарга карата 0,85 күләмендә төзәтмәләр коэффициентын.

2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына әлеге карарның 1 пунктында расланган норматив чыгымнар нигезендә балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларын финанслауны тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы Р.Р. Фасахов

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Башкарма комитетының
2025 елның «02» октябрендәге
215 номерлы карары белән
расланган

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының балаларга сәнгать-эстетик юнәлештәге өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнар

| Өстәмә белем бирү программасының юнәлеше | Территориаль урнашуы | Норматив чыгымнар (бер укучыга бер елга сумнарда) | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | өч еллык уку вакыты | дүрт еллык уку вакыты | биш еллык уку вакыты | җиде-еллык уку вакыты | сигезьеллык укыту срогы | башлангыч һөнәри юнәлеш бирү |
| Музыкаль сәнгать | авыл җирлеге | 104 247 | 99 756 | 101 088 | 116 348 | 118 295 | 157 454 |
| Сынлы сәнгать | авыл җирлеге | | 52 078 | 44 324 | 41 001 | 45 254 | 103 657 |
| Хореография сәнгате | авыл җирлеге | | | 101 666 | 82 983 | 85 697 | 358 407 |
| Гомуми эстетик сәнгать | авыл җирлеге | | | 45 469 | | | |
| Фольклор сәнгате | авыл җирлеге | | | 105 731 | 101 809 | 102 618 | 173 253 |
| Эстрада-джаз сәнгате | авыл җирлеге | 171 693 | | 157 939 | | | 275 771 |
| Театр сәнгате | авыл җирлеге | 81 056 | 73 192 | 75 802 | 75 771 | 77 485 | 112 534 |